ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2020 г. Заинск № 186

**Зәй муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләрен тоту белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 11 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, "Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр бирүдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар житештерү, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр белән шөгыльләнүчеләргә - субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында" 2016 елның 06 сентябрендәге 887 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. Зәй муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләрен тоту белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга (1нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетын Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.
3. Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составын расларга (2нче кушымта).
4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма

комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында - http//zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында - http//pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма**
**комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

С.Н. Веселов
7-10-27

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
«29» 04. 2020 ел
186 номерлы карарына
1нче кушымта

**Зәй муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләрен тоту белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

**1. Субсидия бирү турында гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, "Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр бирүдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар җитештерү, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр белән шөгыльләнүчеләргә субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында" 2016 елның 06 сентябрендәге 887 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, предприятиеләр эшчәнлеген чикләү чаралары чорына Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә эш көне булмаган көннәрне игълан итү турында» 2020 елның 25 мартындагы 206 номерлы Указы, «Татарстан Республикасында яңа короновирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.03.2020 № 218, 27.03.2020 № 223, 30.03.2020 № 234, 31.03.2020 № 240, 03.04.2020 № 252, 06.04.2020 № 260, 10.04.2020 № 272, 13.04.2020 № 280, 18.04.2020 № 306 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре чыгымнарын финанс белән тәэмин итү максатларында (алга таба - Тәртип) эшләнде һәм ул түбәндәгеләрне билгели:

- субсидия бирү турында гомуми нигезләмәләр;
- субсидия бирү шартлары һәм тәртибе;
- хисап бирүгә карата таләпләр;
- субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне контролдә тотуны гамәлгә ашыру турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык.

1.2. Субсидия чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан (алга таба - муниципаль бюджет) түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә (алга таба - субсидия).

1.3. Субсидия Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан (алга таба - вәкаләтле орган) тиешле финанс елына Зәй муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.4. Субсидияне алучы булып Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре (алга таба - субсидияне алучы) тора.

1.5. Субсидия алучыны сайлап алу критерийләре - предприятие хисабында түбәндәгеләргә акча булмау (җитмәү):

- хезмәт өчен түләү һәм хезмәт өчен түләүне хисаплау (штат расписаниесе нигезендә хезмәткәрләргә хезмәт хакы һәм хезмәт өчен түләү буенча түләүләр);

- коммуналь хезмәтләр күрсәтү (электр белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу).

## 2. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидия алучы план чорында субсидия бирүгә вәкаләтле органга түбәндәге документларны җибәрә:

- субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына кадәр бирелгән тиешле рәвештә расланган юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

- субсидия алучы Уставының тиешенчә расланган күчермәсе;

- субсидия алучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан имзаланган, субсидия алучы тарафыннан әлеге тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль бюджеттан акча алмавы турында, шартнамә төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына туры китереп, ирекле формада төзелгән белешмә.

Субсидия алучы бирелгән документларның дөреслеге өчен җавап тота.

2.2. Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе, Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль унитар предприятиеләрен тотуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында, тапшырылган документларны 4 (дүрт) эш көне дәвамында тикшерә.

2.2.1. Күрсәтмәләр булган очракта, документлар субсидия алучыга аларны төзәтү өчен кире кайтарыла. Субсидия алучы, күрсәтмәләрне бетергәннән соң, субсидия алу өчен вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.3. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) әлеге тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

2) субсидия алучының әлеге тәртипнең 2.7 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

3) субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

2.4. Субсидия күләме вәкаләтле органга Зәй муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләрендә билгеләнә.

2.5. Субсидия предприятиене тотуга бәйле чыгымнарның түбәндәге юнәлешләрен финанс белән тәэмин итү чыганагы булып тора (100% күләмендә):

- хезмәт өчен түләү һәм хезмәт өчен түләүне хисаплау (штат расписаниесе нигезендә хезмәткәрләргә хезмәт хакы һәм хезмәт өчен түләү буенча түләүләр);

- күрсәтелгән коммуналь хезмәтләргә түләү (электр белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу).

2.6. Субсидия алучы тиешле таләпләргә җавап биргәндә, вәкаләтле орган 3 (өч) эш көне эчендә субсидия алучы белән типлаштырылган форма нигезендә муниципаль бюджеттан субсидия бирү турында шартнамә (алга таба - шартнамә) төзи (әлеге тәртипкә 1нче кушымта).

2.7. Субсидия алучы килешү төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына җавап бирергә тиешле таләпләр:

1) чит ил юридик заты, шулай ук салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яисә) мондый юридик затка карата финанс операцияләре (офшор зоналары) уздырганда мәгълүматны ачуны һәм тапшыруны күз алдында тотмаучы, теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннанраслана торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территория булып торган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше тулаем алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик затлары субсидия алучы була алмый.

2) субсидия алучы әлеге тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль бюджеттан акча алырга тиеш түгел;

3) субсидияне алучы үзгәртеп кору, ябылу процессында булырга тиеш түгел, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган.

2.8. Субсидиянең айлык күләме вәкаләтле органга субсидия алучы тарафыннан бирелгән гариза буенча әлеге тәртипнең 2нче кушымтасы (алга таба - гариза) нигезендә һәр айның 25 числосына кадәр билгеләнә. Гаризага җитәкче һәм баш хисапчы кул куйган документларның таныкланган күчермәләре белән исәп-хисапны раслап, субсидиянең айлык хисабы теркәлә.

2.9. Вәкаләтле орган әлеге тәртипнең 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң 3 (өч) эш көне эчендә планлаштырыла торган чыгымнарның нигезләмәнең 2.5 пунктында күрсәтелгән чыгымнар

юнәлешләренә туры килүен тикшерә һәм субсидияне күчерү турында карар кабул итә, ә әлеге тәртипнең 2.10 пунктында каралган очракларда, алучыга субсидияне күчерүдән баш тарту турында мотивлаштырылган хат җибәрә.

2.10. Субсидияне күчерүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- Субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

-планлаштырылган чыгымнарның әлеге тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән чыгым юнәлешләренә туры килмәве.

2.11. Субсидияне күчерү кредит оешмасында ачылган һәм килешүдә күрсәтелгән субсидия алучының исәп-хисап счетына вәкаләтле органга әлеге тәртипнең 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырганнан соң 10 (ун) эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.12. Субсидия алучыга муниципаль бюджеттан алынган средстволар хисабына чит ил валютасы сатып алу тыела, моңа хокук актында билгеләнгән югары технологияле чит ил җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләр керми.

2.13. Субсидия алучы тарафыннан чыгымнарны аерым исәпкә алуны алып бару килешүгә кертелә торган мәҗбүри шарт булып тора.

2.14. Хисап финанс чорында (ай, квартал) файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешен (товарлар җитештерүгә (реализацияләүгә), эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидиядән тыш, субсидия алучының алган акчаларыннан субсидия бирүнең шартлары һәм (яисә) максатлары нигезендә файдалануны раслау таләбе белән), финанс белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру һәм мондый нигезләмәләрне вәкаләтле орган, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы белән килештереп, әлеге чараларга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә, килешүгә кертү мөмкинлеге бирелә.

## 3. Хисап бирүгә таләп

3.1. Бирелгән субсидияне тиешле максатларда файдалануны контрольдә тоту максатларында, субсидия алучы ай саен хисап аеннан соң килгән айның 5 (биш) эш көне эчендә, финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында вәкаләтле органга әлеге тәртипнең 3нче кушымтасы нигезендә хисап бирә.

3.2. Субсидия алучы бирелгән документларның дөреслеге өчен җаваплы.

## 4. Субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру буенча таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

3.1. Вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органнары субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыралар.

3.2. Субсидия алучы субсидия бирүче вәкаләтле орган һәм субсидия алучы тарафыннан аларны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәү өлешендә муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан мәҗбүри тикшерүне уздыру өчен кирәкле барлык документацияне тапшырырга тиеш.

3.3. Субсидия алучы әлеге тәртиптә билгеләнгән шартларны, шулай ук шартнамәдә каралган шартларны һәм йөкләмәләрне бозган очракта, вәкаләтле орган килешүне тиешле тәртиптә өзү турында карар кабул итә.

3.4. Вәкаләтле орган һәм (яисә) муниципаль финанс тикшерүе органнары субсидия алучы тарафыннан әлеге тәртип һәм килешүдә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртипне бозуны ачыклаган очракта, субсидия алучы акчаларны вәкаләтле органның шәхси счетына акча күчерү юлы белән муниципаль бюджетка кире кайтаруны мондый кире кайтару турында идарәдән һәм (яисә) муниципаль финанс контроле органнарыннан хәбәр алынганнан соң 30 банк көне эчендә башкарырга тиеш.

3.5. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия суммасы хисап чорыннан соң килүче финанс елының 1 февраленә кадәр муниципаль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

3.6. Субсидия алучы акчалата средстволарны ирекле тәртиптә кире кайтарудан баш тарткан очракта, түләтү Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә башкарыла.

Зәй муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләрен тоту белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 1нче кушымта

## Зәй муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләрен тоту белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында шартнамә

«__» _____________ 20__ ел №  ________________________
*(төзү датасы)* *(номер)*

_______________________________________________________________________________,
*(Зәй муниципаль районы бюджеты акчаларын алучыга субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән башкарма органның исеме,*

алга таба «вәкаләтле орган» дип аталып, _________________________________________________________ исеменнән
*(җитәкче вазыйфасының исеме)*

______________________________________________, нигезендә эш итүче
*(җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)*

______________________________________________________________,
*(Башкарма комитет турында нигезләмә)*

бер яктан һәм ___________________________________________________,
*(оешманың исеме)*

алга таба «субсидия алучы» дип аталып, __________________________
*(җитәкче вазыйфасының исеме)*

_________________________________________________________, нигезендә
*(фамилия, имя, отчество (при наличии) руководителя Учреждения или уполномоченного им лица)*

эш итә торган______________________________________________________,
*(оешманың уставы яисә башка вәкаләтле документ)*

алга таба «яклар» дип исемләнеп, икенче яктан, түбәндәгеләр турында шушы шартнамәне төзеделәр.

### I.Шартнамә предметы

1.1. Әлеге шартнамә предметы булып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләренә чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидия (алга таба - субсидия) бирү тора.

### II. Субсидия бирү тәртибе, шартлары

2.1. Субсидия Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләренә чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә.

2.2. Субсидия вәкаләтле органга Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе кодлары буенча Зәй муниципаль районы

бюджеты акчаларын алучы буларак җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләрендә (алга таба - БК кодлары) түбәндәге күләмдә бирелә:

БК коды буенча ________ ________ (_________________________) сум.

*(БК коды)* *( сумма сүз белән)*

III. Субсидияне күчерү тәртибе

3.1. Субсидия субсидия бирү тәртибе нигезендә бирелә.

Субсидияне күчерү Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетыны, тәртипнең 2.8 пунктында күрсәтелгән гариза алучы тарафыннан вәкаләтле органга субсидия бирелгән көннән соң килүче 10 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

IV. Якларның үзара хезмәттәшлеге

4.1. Вәкаләтле орган түбәндәгеләрне үз өстенә ала:

4.1.1. әлеге шартнамәнең II бүлеге нигезендә субсидия бирүне тәэмин итү;

4.1.2. әлеге шартнамәнең VII бүлегендә күрсәтелгән счетка субсидия күчермәсе теркәлгән документлар белән гариза кергәннән соң ай саен бирүне тәэмин итү;

4.1.3. әлеге шартнамәдә каралган тәртиптә субсидиянең тиешле максатка тотылуын тикшереп тору;

4.1.4. әлеге шартнамәнең үтәлеше белән бәйле субсидия алучының тәкъдимнәрен карау, шул исәптән субсидияләр күләмен үзгәртү буенча һәм тәкъдимнәрне алганнан соң, ___ эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия алучыга аларны карау нәтиҗәләре буенча карарларны җибәрү;

4.1.5. Россия Федерациясе бюджет законнарында, тәртип һәм әлеге шартнамәдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә.

4.2. Вәкаләтле орган:

4.2.1. Субсидия алучыдан субсидиянең үтәлешен тикшереп тору өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны соратып ала;

4.2.2. Россия Федерациясе бюджет законнарында, тәртиптә һәм әлеге шартнамәдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашыра;

4.3. Субсидия алучы башкара:

4.3.1. вәкаләтле орган гарызнамәсе буенча 15 көн эчендә әлеге шартнамәнең 4.1.3 пунктында каралган контрольне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны бирү;

4.3.2. вәкаләтле орган субсидияләрне кире кайтару турында сораткannan соң 30 эш көне эчендә субсидияне кире кайтару;

4.3.3. вәкаләтле органга түбәндәгеләрне бирергә, үтәргә:

4.3.3.1. оешма чыгымнары турында хисап;

4.3.3.2. Россия Федерациясе бюджет законнарында, тәртип һәм әлеге шартнамәдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәү;

4.4. Субсидия алучы:

4.4.1. вәкаләтле органга әлеге шартнамәне үтәү буенча тәкъдимнәр

җибәрә, шул исәптән субсидия күләмен үзгәртү буенча;

4.4.2. әлеге шартнамәнең үтәлешенә бәйле рәвештә аңлатмалар алу максатларында вәкаләтле органга мөрәҗәгать итә;

4.4.3. Россия Федерациясе бюджет законнарында, нигезләмәдә һәм әлеге шартнамәдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашыра.

## V. Якларның җаваплылыгы

5.1. Әлеге шартнамә буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

5.2. Яклар тарафыннан әлеге шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылык турында башка нигезләмәләр.

## VI. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Килешүне өзү якларның килешүе буенча гамәлгә ашырыла һәм әлеге шартнамәне өзү турында килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

6.2. Әлеге шартнамәне үтәү белән бәйле рәвештә, яклар арасында барлыкка килә торган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкин булганча, тиешле беркетмәләрне яисә башка документларны рәсмиләштереп, сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешелмәгән очракта, яклар арасында бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

6.3. Әлеге шартнамә якларның һәркайсы исеменнән эш итәргә хокукы булган затлар тарафыннан имза салынган датадан үз көченә керә, әмма әлеге шартнамәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын җиткергәннән алдарак түгел, һәм якларның әлеге шартнамә буенча үз йөкләмәләрен тулысынча үтәгәнгә кадәр гамәлдә була.

6.4. Әлеге шартнамә ике нөсхәдә кәгазь документ рәвешендә якларның һәркайсы өчен берәр данәдә төзелде.

## VII. Якларның түләү реквизитлары

| | |
|---|---|
| Вәкаләтле органНЫҢ исеме<br>ОГРН, ОКТМО | Оешманың исеме<br>ОГРН, ОКТМО |
| Урнашу урыны: | Урнашу урыны: |
| ИНН/КПП | ИНН/КПП |
| Түләү реквизитлары:<br>Түләүченең исеме<br>Россия Банкы учреждениесе исеме, БИК,<br>Исәп-хисап счеты, | Түләү реквизитлары:<br>Аучының исеме,<br>Россия Банкы учреждениесе исеме, БИК,<br>Корреспондент счеты, |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет | Исәп-хисап счеты, |

Якларның имзалары

| Кыскартылган исеме | Кыскартылган исеме |
|---|---|
| _____________/ _______________<br>(имза) (ФИА) | ______________/ ________________<br>(имза) (ФИА) |

Зәй муниципаль районы
муниципаль унитар
предприятиеләрен тоту белән
бәйле чыгымнарны финанс
белән тәэмин итү максатларында
Зәй муниципаль районы
бюджетыннан субсидия бирү
тәртибенә 2нче кушымта
(Субсидия алучының
бланкында)

2020 елның ___________ субсидия алу өчен
(ае)

ГАРИЗА

Субсидия бирү турында ____ ________ ____ номерлы шартнамә нигезендә, Зәй муниципаль районының ___________ муниципаль унитар предприятиесенә____________ аена ______ сум күләмендә субсидия күчерүне сорыйм.

Субсидиянең айлык күләмен исәпләү кушымта итеп бирелә <*>.

(атальшы житәкче вазифасы) (имза)

(Ф.И.А.)

| | | |
|---|---|---|
| Баш хисапчы | ______________ ____ (имза) | __________________________ ____ (Ф.И.А.) |

---

<*> Исәп әлеге Тәртиптә билгеләнгән чыгымнар юнәлешләре буенча төзелә

Зәй муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләрен тоту белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 3нче кушымта

Республикасы Зәй муниципаль районының «______________» муниципаль унитар предприятиесен тотуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында субсидиядән файдалану турында хисап

Отчет чоры: ___________ башлап ____________ кадәр
Хисап чоры башына субсидиянең калган чаралары: ________ сум.

| Чыгымнар статьяларының аталышы | Кредит орның исеме | Бюджет ассигнованиеләре исәбеннән түләнергә тиешле йөкләмәләр реестры нигезендә бурыч күләме, сумнарда | Бурычның барлыкка килүен раслый торган документларның реквизитлары | Бурычны каплауны раслый торган түләү документының номеры һәм датасы | Түләү документы суммасы, сумнарда | Субсидиянең файдаланылмаган калдыгы ____________ (хисап төзү датасына) | Субсидиянең файдаланылмаган калдыгы барлыкка килүнең сәбәпләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7=3-6 | 8 |
| | | | | | | | |
| БАРЫСЫ: | | | | | | | |

Субсидиядән файдалануны раслаучы хисап материаллары Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырылды, саклау өчен җаваплы булып тора ______________________________
(Ф.И.А., хезмәткәрнең вазыйфасы)

МУП җитәкчесе «______________________» _____________/_____________/

МУП баш хисапчысы «_______________» _____________/_____________/
"__" ________ 20__ г.
М.У.
Вәкаләтле органның хисапны кабул итү һәм тикшерү турында билгесе _______________

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
«29» 04. 2020 ел
186 номерлы карарына
2нче кушымта

**Зәй муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләрен тоту белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Захарова М.И. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә һәм эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары - комиссия рәисе. |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Нифатов Н.А. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Архипова Р.М. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |
| Городнова О.В. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| Веселов С.Н. | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының баш белгече |